ЭП
Подписан: Хасанова Рузиля Илдаровна
DN: C=RU, OU=образовательное учреждение, O="МОУ "" Нурумбальская средняя (полная) общеобразовательная школа""", CN=Хасанова Рузиля Илдаровна, E=nurumbal@mail.ru
Основание: Я являюсь автором этого документа
Местоположение: Нурумбал
Дата: 2021-12-14 13:45:17
Foxit Reader Версия: 9.7.2

Отдел образования Администрации Моркинского муниципального района Республики Марий Эл
Муниципальное образовательное учреждение «Нурумбальская средняя общеобразовательная школа»

Рассмотрено
педагогическим советом
МОУ «Нурумбальская СОШ»
от «28» август 2021 г.
Протокол №6

Утверждаю
Директор школы: ________ Р.И.Хасанова

# Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа «Занимательный татарский язык»

Направленность программы: художественная
Уровень программы: базовый
Категория и возраст обучающихся: 8-16 лет
Срок освоения программы: 1 год
Объем часов: 34 часа
Разработчик программы: Хатиуллина Гольсара Шарифулловна, учитель татарского языка и литературы

д.Нурумбал
2021 г.

Отдел образования Администрации Моркинского муниципального района
Республики Марий Эл
Муниципальное образовательное учреждение «Нурумбальская средняя общеобразовательная школа»

Рассмотрено
педагогическим советом
МОУ «Нурумбальская СОШ»
от «28» август 2021 г.
Протокол №6

Утверждаю
Директор школы:_______Р.И.Хасанова

# Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа «Занимательный татарский язык»

Направленность программы: художественная
Уровень программы: базовый
Категория и возраст обучающихся: 8-16 лет
Срок освоения программы: 1 год
Объем часов: 34 часа
Разработчик программы: Хатиуллина Гольсара Шарифулловна, учитель татарского языка и литературы

д.Нурумбал
2021 г.

# *Список учащихся:*

1. ***Галимов Камиль 2 кл***
2. ***Иванова Азалия 3 кл***
3. ***Мухаметов Адель 3 кл***
4. ***Губадуллин Айнур 3 кл***
5. ***Латыпова Света 4 кл***
6. ***Галимов Рамиль***
7. ***Габтрафиков Айнур 4 кл***
8. ***Саттаров Рамзиль 4 кл.***
9. ***Хабибрахманов Алмаз 4 кл***
10. ***Ахметзянов Замир 4 кл***
11. ***Зинатуллин Эмиль 5 кл***
12. ***Хасбиуллин Камиль 5 кл***
13. ***Латыпов Азат 6 кл***
14. ***Низамиева Камила 6 кл***
15. ***Зинатуллина Эльмира 7 кл***
16. ***Хасбиуллин Рустам 7 кл***
17. ***Фалзянов Ильдар 9 кл***
18. ***Хабибрахманов Азат 9 кл***
19. ***Хабибрахманов Ильшат 10 к***

**Рецензия**

**на программу кружка «Занимательный татарский язык»**

Актуальность разработки и реализации программы «Занимательный татарский язык» обусловлена проблемами нравственного развития детей. Программа является хорошим дополнением к школьным курсам татарского языка и литературы, способствует формированию нравственной индивидуальности воспитанника. Образовательная программа «Занимательный татарский язык» предназначена для работы с учащимися в возрасте 9-11лет и рассчитана на один год обучения.

Пояснительная записка включает в себя цели, задачи, основные методы, предполагаемые результаты и оценку результативности программы. Так же здесь представлен тематический план, состоящий из 34 тем, рассчитанных на 34 учебных часов. В содержательной части программы раскрыты основные темы занятий, их содержание и обоснование, даны основные характеристики организационных условий, необходимых для получения образовательного результата. Список литературы соответствует содержанию программы, подходит и для педагога, и для детей.

Представленная к рецензии программа соответствует специфике дополнительного образования, стимулирует познавательную деятельность ребенка, развивает коммуникативные умения, создаёт социокультурную среду общения, способствует развитию творческих способностей личности, стимулирует стремление к самостоятельной деятельности и самообразованию.

Программа имеет приложения, которые подтверждают факт её успешной реализации. Материал программы «Занимательный татарский язык» составлен на основе программы татарского языка и литературы и адаптирован для восприятия детей младшей школьной возрастной группы, а также часы работы по программе соответствуют современным требованиям СанПина.

Новизна предложенной программы состоит в том, что она способствует социализации личности, создает условия для формирования социальных компетентностей младших школьников. Её уникальность в преемственности, т.к. после обучения в начальных классах у школьников есть возможность продолжить работу в детской общественной организации «В мире слов», открытой на базе школы для 5–7 классов, а затем - в «Эрудит» для 8 – 11 классов.

Тематический план по соотношению практических и теоретических часов соответствует современным требованиям, предъявляемым к образовательным программам дополнительного образования детей.

Программа рекомендована к использованию.

**Рецензия**
**на программу кружка «Занимательный татарский язык»**

Программа «Занимательный татарский язык» является программой гуманитарной направленности. Данная программа предназначена для учащихся 2– 5 классов. Наполняемость группы в соответствии с требованиями СанПиНа 19 человек. Занятия проводятся 1 раза в неделю. Программа рассчитана на 34 часа в год. Программа «занимательный татарский язык» отличается грамотным оформлением, чёткостью структуры. Программа носит целостный характер, выделены структурные части, основные компоненты программы, согласованы цели и способы их достижения.

«Пояснительная записка» включает в себя несколько взаимосвязанных компонентов: обоснование программы, в котором отражена актуальность, новизна программы, цели и задачи, условия реализации, материально-техническое обеспечение, основные формы и методы работы с детьми, ожидаемые результаты, формы, методы. Обзорно раскрыто содержание программы.

«Учебный план» включает последовательность изучаемых тематических блоков с указанием общего количества часов и количества часов на теоретические и практические занятия.

«Содержание программы» раскрывает содержание по каждому тематическому блоку. Тематический план учитывает основные требования к организации образовательного процесса в учреждении дополнительного образования детей. Основные темы занятий раскрыты в полном объеме. Отведено время на вводное занятие, подведение итогов.

«Методическое обеспечение» программы в полной мере характеризует педагогические, психологические, организационные условия, необходимые для получения образовательного результата. Формой проведения итогов реализации программы является творческая работа учащихся. Оценка результатов освоения материалов определяется уровнем знаний, умений и навыков, определенных в программе.

Программа актуальна, т.к. содействует развитию воображения и фантазии учащихся, пространственного мышления. Она способствует раскрытию творческого потенциала личности, вносит вклад в процесс формирования мышления ребёнка, развития языка, его эмоциональной отзывчивости.

Практические занятия развивают умение наблюдать, анализировать, учат понимать прекрасное. Кроме того, у детей пробуждается интерес к языку, говорению, любовь и уважение к культуре своего народа.

В программе представлен список литературы. Список рекомендуемой литературы достаточно полон, доступен для адресата.

Программа актуальна для работы с детьми младшего школьного возраста. Рекомендуется к использованию.

## Аңлатма язуы

Халык педагогикасы балаларга хезмәт, әхлак, акыл, физик һәм эстетик тәрбия бирүне күздә тота. Алар бер-берсе белән нык бәйләнгән.Тәрбия бербөтен,күпкырлы, киң колачлы.Ул һәрвакыт, һәр җирдә: урамда, өйдә, мәктәптә, һәрбер дәрестә, һәр тәнәфестә тормышка ашырыла. Димәк, без бу чорда тәрбия эшен аеруча зур җаваплылык белән, эзлекле алып барырга тиеш Түгәрәк эшчәнлеге ярдәмендә балаларны халкыбызның культура мирасы белән таныштыруны, аларның рухын баетуны, әхлагын камилләштерүне һәм төрле өлкәләрдә сәләтен үстерүнеүз алдыма максат итеп куйдым.Эшне түбәндәге юнәлешләрдә алып барам:

**-безнең тарихыбыз, туган ягыбыз;**

**-халкыбызның уен, җыр, бию һәм музыка сәнгате;**

**-халык авыз иҗаты.**

Шушы максатларны тормышка ашыру максатыннан, мин мәктәп компонентыннан бирелгән сәгатьләрне уздыру өчен махсус курс программасын төзедем. Махсус курсның исеме “Чишмә” дип атала. Программа рус мәктәпләренең 2-10 нче сыйныфларында укучы рус һәм татар балалары өчен 34 сәгатькә исәпләнгән. Татар әдәбияты дәресләрендә әсәрләре белән укучыларны уйланырга мәҗбүр иткән, әхлак сыйфатларын тәрбияләгән бүгенге көн авторларына зур урын бирү зарур. Шуны истә тотып мин программага татар халкының танылган язучыларының әсәрләрен, экиятләрен дә керттем.

Халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны укуга яки әңгәмә үткәрүгә генә кайтарып калдырмыйча, эш формаларын һәм алымнарын төрлечә үзгәртәм.Табышмаклар кичәсе, экиятләрне язу һәм сәхнәләштерү, бәетләр иҗат итүче кешеләр белән очрашу түгәрәк эшен җанлы һәм кызыклы итеп оештырырга ярдәм итә.

Бүгенге көндә укытучыларының төп бурычы - балаларны белемле, рухи яктан бай, әхлаклы, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Бу бурычлар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Шулар арасында иң әһәмиятлесе,үтемлесе һәм нәтиҗәлесе-уеннар.

“Уен-баланың тормышка әзерләнү күнекмәсе ул. Уеннар балага зур файда китерәләр, алар ярдәмендә ул үзенең характерына нигез ташы булып урнашып кала торган гадәтләргә, күнекмәләргә өйрәнә, моның өстенә бу уеннар балада, гадәттә, зур канәгатьләнү хисе уяталар”,- дип язган профессор П.Ф.Лесгафт. Дөрестән дә, уеннар, бер яктан, физик тәрбия чарасы булса, икенчедән, күп кенә уеннар эстетик тойгылар тәрбияләүгә зур ярдәм итә. Хәрәкәтләрнең төгәллеге, уенның сүзләрен сәнгатьле итеп әйтү, балаларның төрле образлар башкарулары - болар барысы да балаларда канәгатьләнү хисләре уята, матурлыкны аңларга ярдәм итә. Алай гына да түгел, уен вакытында баланың күңеле күтәренке, көр була, һәм бу халәт аның нерв системасына уңай йогынты ясый. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әверелдерә. Танылган шәхесләребезнең берсе – Ризаэддин Фәхреддин балаларга язган үгет – нәсыйхәтендә: “ Балаларның тәрбиялесе илә тәрбиясезе уйнаган вакытларында бик ачык беленер. Аның өчен уйнаган чакларында балалар бик каты ихтыярлы булырлар, зурлардан курку кеби нәрсәләр күңелләреннән чыгып та китәр”, - дигән.

Халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш-көнкүреше чагылыш тапкан бу уеннар балаларда үз көченә ышану, күмәклек, ярдәмләшү, шулай ук кешелеклелек, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар да тәрбияли. Шигъри такмаклы уеннар балаларның хәрәкәтчәнлеген арттыру белән бергә, сөйләм телен дә үстерә, уен барышында һәммәсенә дә катнашырга мөмкинлек туа.

Укучыларда үзләренең иҗади активлыгын гамәлгә ашыру, нәрсәгә сәләтле, ни дәрәҗәдә зыялы булуларын һәм нәрсәгә ирешүләрен күрсәтү ихтыяҗыннан чыгып, программага зыялылык уеннары да кертелде. Төп

игътибар баланың зирәклегенә, логик фикер йөртә алуына, фараз итүенә юнәлтелә. Чөнки кешенең мәгърифәтлелеге белем күләмендә генә түгел, ә аны төрле хәлләрдә куллана алу мөмкинлегендә дә чагылырга тиеш. Соңгы елларда мондый уеннар мәктәп, район, республика күләмендә еш үткәрелә башлады. Укучылар бик теләп катнашалар.

Программа түгәрәк эше буенча укучылар өчен барысы 34 сәгать. Программа биш бүлектән тора: безнең тарихыбыз-5, балалар фольклоры – 14 сәгать, кызыклы грамматика – 1сәгать, шагыйрьләр безнең белән -10 сәгать, кеше һәр яктан гүзәл булырга тиеш -4 сәгать.Укучылар бу түгәрәктә алган белемнәрен 5-8 сыйныфка кадәр “ Сүзләр илендә” исемле түгәрәктә, ә 9-11 кадәр “Эрудит” түгәрәгендә дәвам итә алалар.

Кызыклы грамматика бүлегендәге эш төрләре кушымта буларак бирелә. Кайбер материаллар “Мәгариф” журналыннан, “ Ачык дәрес”, “ Мәгърифәт” газеталарыннан алынган, алар кушымтада искәртелә.

**Максат:**

**Балаларны шәфкатьле, миһербанлы, изгелекле, кешелекле итеп тәрбияләү, сөйләм культурасын, сүз байлыгын арттыру, хәтерен үстерү; укучыларның акыл-зиһен үсешен, ягъни танып-белүен, хәтерен, күзаллау, иҗади логик фикерләү, күзаллау сәләтләрен үстерү; физик һәм рухи яктан сәламәт үстерү.**

Балаларны шәфкатьле, миһербанлы, изгелекле, кешелекле итеп тәрбияләү, сөйләм культурасын, сүз байлыгын арттыру, хәтерен үстерү **максатыннан** программаның теория өлешендә сүзле уеннар, тел шомарткыч такмазалар, тел көрмәкләндергечләр, үртәвечләр, такмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләр, табышмаклар, һәм әкиятләр урын алды. Телдәге кимчелек баланың акыл үсешен тоткарлый, фикер йөртүенә комачаулый, нәтиҗәдә укучы үз фикерен тулысынча сөйләп бирә алмый. Дөрес сөйли алмаган укучы дөрес яза да белми. Бу күнегүләр, мавыктыргыч итеп, уен

формасында оештырыла һәм укучыларның телләрендәге кимчелекләрне төзәтергә ярдәм итәләр.

Укучыларның акыл-зиһен үсешен, ягъни танып- белүен, хәтерен, күзаллау, иҗади логик фикерләү, күзаллау сәләтләрен үстерү **максатыннан** шигъри мәсьәләләр, викториналар, ребуслар, олимпиадалар, конкурс-уеннар кертелде. Бу уеннар барысы да укучыларның үз–үзләренә ышанычын арттыра, шулай ук киләчәктә бердәм дәүләт имтиханнарын бирергә әзерлек тә булып тора.

Укучыларны физик һәм рухи яктан сәламәт үстерү **максатыннан** программаның практика өлешенә төрле хәрәкәтле уеннар кертелде, чөнки физик һәм рухи яктан сәламәт бала гына яхшы укый, ата – анасына һәм җәмгыятькә файда китерә ала.

**Шушы максатлардан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:**

- **укучыларның психологик үзенчәлекләрен истә тотып, уен эшчәнлеген оештыру;**
- **уенны баланың һәр төр эшчәнлегенә кертү;**
- **һәр баланың характерын, темпераментын, шәхси мөмкинлеген, теләген истә тоту;**
- **предметлы уен тирәлеге булдыру.**

**Укучылар белергә тиеш:**

Безнең тарихыбыз, татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятын, мирасын өйрәнү.

- халкыбызның гасырлар дәвамында тупланып килгән поэтик һәм педагогик мирасы булган балалар фольклорын;
- халык педагогикасын;
- әхлак кагыйдәләрен;
- йөгерек санау һәм телдән исәпләү күнекмәләрен;
- әдәп-тәртип кагыйдәләрен.

**Укучылар булдыра алырга тиеш:**

- коммуникатив компетент;
- акыллы, игелекле, гадел, ярдәмчел, яхшы күңелле, хезмәт сөючән;
- туган илне, туган телне ярату;
- әхлаклы, гадел,
- тату, дус;
- зирәк, тапкыр;
- мөстәкыйль;
- җитез, өлгер, кыю;
- физик һәм рухи яктан сәламәт.

**Программа**

**I. Безнең тарихыбыз. (5 сәг.)**

Татар теле –Дәүләт теле.Флаг. Герб. Гимн.

Казанның истәлекле урыннары. Сөембикә манарасы. Кремль..

Татар халкының гореф гадәтләре. Бәйрәмнәр. Йолалар.”Сабантуй”, ”Сөмбелә”,”Нәүрүз”.

Спорт уеннары.

Татар халкының борынгы эш кораллары .

**II . Балалар фольклоры.(14 сәг.)**

**Халык авыз иҗаты, аның төрләре.**

**Уен, аларның төрләре. Сүзле уеннар:** ( CD диск) “Посылка килә”,”Күз, яңгыр”,“Кап та коп”, ”Эшләсәң эш табыла”,”Нәрсә кирәк”, “Шулай буламы, әллә юкмы?”, ”Тигез түгәрәк”, “Бу өйдә нәрсә яши?”, “Бармакларга исем кушу”. **Хәрәкәтле уеннар:** “Чыпчыклар һәм мәче “Түгәрәктә көрәш”, ”Әтәч”, ”Төлке һәм тавыклар”,”Төенчек”, ”Гөрләмеш, яки кача-кача”, “Буш урынлы”, ”Кап та коп”, ”Кабыргалы камчылар”, ” Ак,димә,кара, димә”.

**Такмазалар, аларның туу тарихы, функциясе. Тел шомарткыч такмазалар:** “Әби битен юмаган”, “Барыр идем урманга”, ”Бардым базарга”, “Уймак”,”Өч патшаның бер улы”,”Булган, ди, бер кеше”, ”Үлгән арба”, ”Шаян такмаза”,”Бар иде яшь чаклар”, ”Җыйдык кура җиләк”, ”Бабай бишектә чакта”,”Кызыклы сәфәр”, ”Безнең бабай”, “Дыр” белән “бугай”.

**Такмазалар:** “Борын-борын заманда”,”Давыт”,”Бер өер тай”, ”Әтәч”,”Әби битен юмаган”,“Барыр идем урманга”,”Бардым базарга”,“Уймак”, ”Өч патшаның бер улы”,”Булган, ди, бер кеше”, ”Үлгән арба”.

**Тел көрмәкләндергечләр:** ”Елама, җамалый”,”Чи чия”,”Тимербаевның тае”,”Сирай суы”,”Карамалы малае”, “Кәбирләрнең кәҗәсе”,“Кәбир кызы Кәримә”, ”Карамага карама”,”Бәдрибанат бармагы”,” Бәдерниса бияләе”,”Бытбылдык балалар”, ”Мәче”, ”Мин агамны агалаган”,”Үгезегез мөгезе”, ”Абага”.

**Үртәвечләр. Такмаклар:** “Күкәй салган әтәч”,”Канатлы кәҗә”,“Тәртипсез чебиләр”,”Шапшак сарыклар”“Аучы кәҗәләр”,”Ялкау ата каз”,”Печән ашаучы казлар”,”Янгынчы песи”,”Эшчән песи”,”Елак каз”,”Усал тавык”,”Гармунчы сарык”, ”Са-ран сыер”,”Юньсез көтүче”,”Бакалар”,”Су ташучы карга”,”Эшлексез чебен”,”Бур кә-җә”, ”Карт песи”,“Елак эти”,”Мәзәк әби”, ”Өтерге”,”Хәйләкәр такмакчы”,”Ипи-хлеб”.

“Зур шалкан” әкиятен ( Күмәк уен ), Абдулла Алишның “ Куян кызы” әкиятен сәхнәләш-терү.

**Әкият-табышмаклар:** “Өч роза”,”Илдә булмаган ат”. **Табышмак – сораулар:** ”,”Бездән сорау сездән-җавап”,”Географияне беләсезме?”, ”Уналты шакмак”,”Шаян табышмак-сораулар”.

**Мәкальләр һәм әйтемнәр:** Ата-ана, ата-ана һәм балалар, ана һәм бала, ата һәм бала, юньле бала һәм юньсез-игелексез балалар, эш-хезмәт, Туган ил турында, галиҗәнап икмәк, белем-гыйлем, китап, уку-язу, табигать күренешләре.

**Мәзәкләр:** Ата-ана һәм балалар. Мактанчык, ялганчы, куркак кешеләр. Ялкау, эшкә җавапсыз карау-чылар, белемсезләр, наданнар.

**Табышмаклар:** Уку-язу турында. Сорау табышмаклар. Тел турында. Табигать күренешләре, ел фасыллары. Үсемлекләр, куаклар, агачлар. Бөҗәкләр, кошлар, җәнлекләр, йорт хайваннары. Яшелчә-җиләк җимеш. Тапкырлар, зирәкләр өчен табышмаклар.

**7нче апрель - Сәламәтлек көне.** К.Чуковскийның “Юындыр”(DVD диск) фильмын карау, эчтәлеге буенча фикер алышу, нәтиҗә ясау.

**Зоологик эстафета** (уен-ярыш).

**Татар халык әкиятләре тыңлау** ( CD диск). Абдулла Алишның“Бал корты һәм Шөпшә” ”Сертотмас үрдәк” әкиятләрен тыңлау, эчтәлеге буенча фикер алышу, нәтиҗә ясау. Әкиятләр язу,өйрәнү, сәхнәләштерү.

**III. Кызыклы грамматика.(1 сәг.)**

**Хикмәтле математика. Шигъри мәсьәләләр:** “Нинди тизлектә очалар”,”Ничә яшьтә”, “Ничә сәгатьтә куып җитә?”,”Ничә гөмбәне юк

иткәннәр?”,”Күпме яфрак ашарлар”, ”Ничәшәр сәгать эшлиләр?”,”Күпме таралган?”, ”Һәркайсы ничәшәр”.

**Викторина:** Нәрсә? Кайда? Кайчан?

**Могҗизалар иленә сәяхәт.** Шарль Перроның”Көлкәй”(Золушка) әкиятенә сәяхәт. Әкият герое каршындагы кыенлыклар математик мисал, мәсьәләләр, башваткычлар рәвешендә бирелә.

**Ребуслар**, аларны укуның элементар кагыйдәләре, алымнары. Ребуслар чишү.

**Хәрәкәтле уеннар:** “Самовар”, Ябалаклар,күбәләкләр,бөҗәкләр”, “ Тасманы ал”, “Ике суык”, .”Күз бәйләш”, “Алырмын кош”, “Кәбестә”, “ Очты, очты ”, “Туп йөртеш”, “Челтәр элдем читәнгә”, ” Почмак алыш”, ” Чума үрдәк, чума каз “, ” Буяу сатышлы “,
” Өлгерсәң өлгер “.

**Дидактик - уеннар:** «Зирәк тиен”

**Ярыш – уен:** Уеннарда – хәрәкәт, хәрәкәттә - бәрәкәт.

Язгы һәм җәйге сынамышлар

**IV.Шагыйрьләр безнең белән.(10сәг.)**

Г.Тукайның иҗатын өйрәнү.Призентация “Туган як серләре” ;Г.Тукай әкиятләре.”Шүрәле”.Призентация ясау; М.Җәлилнең тормыш юлы, призентация карау; М.Җәлилнең фронтан язган хатларын, әкиятләрен өйрәнү; Муса Җәлилнең әнисе белән очрашу вакыйгасы һәм алар кичергән хисләр, шагыйрь күңелендәге әрнү сагыш хисләренең бирелеше турында фикер алышу; Практик дәрес

“Татар шагыйрьләре - тыйнаклык үрнәге” дигән темага эссе; Рус халык әкиятләрен өйрәнү.”Колобок”, “Теремок” Рус халык әкиятләрен (”Колобок”, “Теремок) сәхнәләштерү; Якташ язучылыр белән танышу; Хәбибуллина М.И.; Н.Гыйматдинова.; Х.Туфан; Яшь драматург Илгиз Зәйниев.

**V. Кеше һәр яктан гүзәл булырга тиеш (4сәг.)**

Әдәбиятта” ана” темасының чагылышы турында фикер алышу; Бәхет турында уйланулар;

“Миңа үрнәк булырдай кеше” темасына презентацияләр бәйгесе; укучылар иҗаты; иҗади эшләр,эсселар. презентацияләр конкурсы; йомгаклау дәресе; нәтиҗәләр ясау.

**Көтелгән нәтиҗә**

Халык авыз иҗаты әсәрләре аша укучы тормыш фәлсәфәсен төшенә,аның фикерләү сәләте үстерелә, коммуникатив эшчәнлеге арта. Бала үз җирлегендә, үз мөхитендә, үз туган телендә камил тәрбия ала. Балада ныклы үзәк,әхлакый иммунитет формалаша. Сабый күңеле сизгер була: ул яхшылыкка бөтен күңеле белән тартыла, кояшка үрелгән гөл кебек ачыла. Йөзе нурлана, теле тәмләнә, җаны сафлана. Бик оялчан балалар да үз фикерен каушамыйча төгәл әйтеп бирергә, үзләрен кирәкле, файдалы итеп тоярга, сабыр, әдәпле, иркен тотарга өйрәнә.

**Тематик планлаштыру.**

| № | Тема | Сә-гать саны | Шулардан | | Үткәрү урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | тео-рия | прак-тика | |
| | **Безнең тарихыбыз.** | | | | |
| 1-2 | Татар халык орнаментларын өйрәнү | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 3-4 | Татар халык киемнәре | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 5-6 | Тизәйткечләр , әйтемнәр өйрәнү | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 7-8 | Кроссвордлар,грамматик уеннар. | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| | **Шагыйрьләр безнең белән**<br>(Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан кебек атаклы шәхесләр<br>Тормышы турында язылган әсәрләр мисалында) | | | | |
| 9-10 | Г.Тукайның иҗатын өйрәнү.Призентация “Туган як серләре” | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 11-12 | Г.Тукай әкиятләре.”Шүрәле”.Призентация ясау | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 13-14 | М.Җәлилнең тормыш юлы, призентация карау. | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 15-16 | М.Җәлилнең фронтан язган хатларын, әкиятләрен өйрәнү | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 17-18 | Муса Җәлилнең әнисе белән очрашу вакыйгасы һәм алар кичергән хисләр, шагыйрь күңелендәге әрнү сагыш хисләренең бирелеше турында фикер алышу | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 19-20 | Практик дәрес<br>“Татар шагыйрьләре - тыйнаклык үрнәге” дигән темага эссе | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21-22 | “Үги кыз” әкияте. | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 23-24 | “Үги кыз” әкиятен сәхнәләштерү. | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| | **Кеше һәр яктан гүзәл булырга тиеш** | | | | |
| 25-26 | Әдәбиятта” ана” темасының чагылышы турында фикер алышу | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 27-28 | “Бәхет турында уйланулар” темасы | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| 29-30. | Йомгаклау дәресе.Презентацияләрне яклау.Нәтиҗәләр ясау. | 1<br>1 | + | <br>+ | сыйныф бүлмәсе |
| | | | | | |